2005 №11

# Эдуард Касыймов — публицист

***(Әдипнең тууына 75 ел тулу уңаеннан)***

**Осталык дип аталган олуг хәзинәне табу, туплау, өйрәнү һәм кулленуның йөзләрчә алым, юллары бар. Шуларның берсен без Чаллыда таптык. Казан дәүләт университетының Чаллы филиалында татар журналистикасы бүлеге ачылган иде.**

**Студентлар Чаллы төбәге әдипләренең иҗаты белән төплерәк, якыннанрак кызыксыналар икән. Шуннан инде: «Ә нигә без программада каралган мәгълүм әдипләрнең иҗат остаханәсе белән генә чикләнәбез, мәктәп елларыннан ук таныш, хәтта үзләрен дә белеп-күреп үскән әдипләрнең хезмәтләрен, иҗат үзенчәлекләрен анализламыйбыз?» дигән фикер кабынып китте.**

**Бүгенге язмабыз күренекле язучы, публицист һәм галим Эдуард Касыймовның тууына 75 ел тулган көннәрдә аның иҗатына, осталык тәҗрибәсенә багышлана. Әдипнең әсәрләрен кызыксынып укып, осталыгының төрле якларын кулдан килгәнчә анализлап, киләчәктә үзебезгә ярап куярдай осталык бөртекләрен эзләп табу максатын куйдык.**

## Кем ул Эдуард Касыймов?

Әсәрләрне анализларга, безне кызыксындырган үзенчәлекләрне табарга керешкәнче, аларны язган әдибебезнең тәрҗемәи хәленә, тормыш хәл-әхвәлләренә кыскача гына күз салу хәерле булыр. Бу юнәлештә без аңа материал, чыганаклар эзләү белән мавыкмадык, мәгълүм чыганакларга, әле исән-сау шаһитларның истәлек-хатирәләренә таяндык. Дөресен әйткәндә, Эдуард Касыймовның иҗаты, биографиясе дә чордаш-кордаш каләмдәшләре белән чагыштырганда азрак өйрәнелгән, дигән фикер белән тулаем килешсәк тә, аңа караган шактый кызыклы язмаларны барлавыбызны икрар итүне кирәк санnetwork... 

Эдуард Касыймов татар теленең төп сөйләмнәреннән берсен тәшкил иткән тарихи үзенчәлекле, бай Нократ сөйләменең үзәгендә — Нократ авылында 1930 елның 9 ноябрендә туа. Тел тоемлау, аны куллану

сәләте әти-әнисеннән килә. Әтисе укымышлы, аралашучан, актив зат буларак (авыл советын җитәкли, колхоз оештыруда катнаша, укытучы була), бу сыйфатларын балаларына да йоктыра. Тик Эдуардка әтисе мәктәбендә озак укырга туры килми — мәктәп директоры Салихҗан Касыймов «халык дошманы»на әйләнә, кулга алынып, 1937 елны атыла.

Эдуардның әнисе, балаларын ияртеп, туган каласы Малмыжга китәргә, туган-тумачага сыенырга мәҗбүр була. Эдуард шунда җидееллык татар мәктәбендә сигезне, урыс урта мәктәбендә унынчы классны тәмамлый.

1948—1953 елларда Э.Касыймов — В.И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты студенты. Биредә аның язучылык сәләте ачылганнан-ачыла бара. Сабакташларының берсе моның сәбәбен болайрак аңлата: туган төбәгендә ана телен өйрәнеп үсүе, бик яшьли кайгы-хәсрәт күрүе, ятимлекнең ачысын татуы, әйләнәтирәгә ачык күз белән карарга, кеше танырга күнегүе. Адым саен гаделсезлек күрүләр, намуссызлыкка юлыгулар Эдуардның күңелендә каршылыклы уйлар һәм хисләр тудыра. Өстәвенә, җәмгыятебездә бер төрле сөйләп тә, бөтенләй икенче төрле эшләүнең хуплануы, ялагайларның юл яруы, икейөзлелекнең чәчәк атуы әлеге хисләрне көннән-көн көчәйтә.

Уку елларында аның беренче тасвирнамә, очерклары, хикәяләре көндәлек матбугатта күренә башлый. Аларга карата ук инде матбугатта «яшь язучыбызның үз тематикасы, үз теле бар», дип, югары бәя бирелсә дә, алар әле, әлбәттә, сәнгати камиллектән шактый ерак була, чөнки, әле тормыш тәҗрибәсе җитешмәгәнлектән, зур проблемалар аңардан ераграк тора. Аннары, «халык дошманы баласы» дигән кара тамга әледән-әле исенә төшеп торса да (мәсәлән, бик теләсә дә, аны аспирантурада калдырмыйлар), бу хәл әле яшь әдипнең күңелендәге өермәне кузгатып җибәрерлек этәргеч булырга тулышып җитә алмаган.

Алар диплом иясе булганда, илленче елларда татар мәктәпләре күпләп ябыла, татар телен укыту да кимегәннән-кими бара. Шунлыктан күп студентка урыс телен укытырга дигән тәкъдим белән килешергә туры килә. Касыймов та 1957 елның җәенә кадәр башта Азнакай эшчеләр поселогында, аннары Киров өлкәсенең Вятские Поляны районына кергән Түбән Шөн авылы урта мәктәбендә урыс теле, тарих укыта, соңыннан шул мәктәпнең уку-укыту бүлеге мөдире булып эшли.

Искә төшерсәк, бу бит шәхес культының кара пәрдәсе ачылып, «халык дошманы» уйдырмасына да яктылык төшкән чор. Университетта фольклордан лекцияләр укыган галим Хәмит Ярми Касыймовны Түбән Шөннән эзләп таба, яңадан Казанга килеп, Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага керергә булыша. Өч елдан инде Эдуард шул институтның татар фольклоры секторында кече гыйльми хезмәткәр булып эшләп китә, халык авыз иҗатының төрле жанрларын җентекләп өйрәнә, диссертация яза.

Шул ук вакытта ул әдәби иҗатны да ташламый. 1959 елда аның беренче мөстәкыйль китабы — балаларга багышланган «Кызыл маяклар» исемле хикәяләр җыентыгы, ә 1962 елда «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналында «Кояш көн дә чыга» повесте басыла.

Бу әсәрендә үк инде авторыбыз кешеләргә игелек кылу, шәфкать-миһербанлык, әдәпле-инсафлы булу, фидакарьлекне хуплау, кыскасы, гуманистик идеяләрне алга сөрә. Сәнгать кешеләре, галимнәр тормышыннан алып язылган һәм драматик вакыйгаларга бай повестьны да укучылар хуплап кабул итте.

Әдипнең күңелендә еллар буе җыелган каршылыклы хисләр — гарьләнү һәм әрнү, мәхәббәт һәм нәфрәт хисләренең тәмам тулышып, ташкындай ургылып чыккан әсәре ул — «Гомер ике килми» романы. Китап язарга материал җыйганда, яшь әдип әтисе үткән юлларны барлый, әтисенең — совет хакимияте өчен тир һәм кан түгеп көрәшкән, колхозлар оештыруда активлык күрсәткән, сабыйларны белемле итү өчен тырышкан укытучының, коммунистның чыннан да бернинди гөнаһсызга кулга алынганына, бинахак атылганына үзе инана. Ул нинди генә җан өшеткеч фактларга юлык-

мый! Үзе кичергәннәре дә азмы! Мәсәлән, Салихҗан Касыймовның 1937 елда ук атылганын әйтмичә, төрмәчеләр, әтиегез безнең төрмәдә утыра, тик хат алышырга ярамый, дигәннәр, ә үзләре озак еллар буе ризык ташыттырганнар. Сабыйларның авызыннан өзеп. Вәхшиләр!

Язучы каләме өр-яңа романлык ягулыкка байый. Тормыш чынбарлыгына, документальлеккә табынган, рухы белән публицист булса да, бу фактларны ул шәхсән үзенә генә кагылган, үзе генә кичерергә тиешле чыганак дип санамый, язучы буларак, инде кыйбла итеп кабул кылган әлеге гуманистик юнәлешкә җигәргә үзендә көч таба. Менә ни сәбәпле автобиографик планда язылган һәм гыйбрәтле язмышларны, тормышның катлаулы, четерекле якларын психологизм алымнары белән сурәтләгән «Гомер ике килми» романы да, әдәбият белгече билгеләп үткәнчә, әдәби җәмәгатьчелектә уңай фикер уята һәм лирик әсәр буларак яңгыраш ала. Бу романда авторның бөтен эрудициясе, тел байлыгы, галимлеге, Нократ сөйләменең үзенчәлекләре гаять тулы чагылыш таба.

Барлык публицист-язучыларга да хас бер сыйфат бар — алар ирешкәннәр белән тукталып торырга, канәгатьләнергә күнекмәгән. Эдуард Касыймов та, әйтик, Хәмит Ярми канаты астында фәнни экспедицияләргә йөри, әкиятләр җыеп, китап итеп чыгара; диссертациясе әзер; Хәмит ага, аны үз урынына фольклор бүлегенә җитәкче итеп калдырып, пенсиягә китәсен игълан итә; доктор диссертациясенә материал әзер, китаплары чыгып тора, яңаларына мая җитәрлек — яши бир тыныч кына Казан каласында...

Юк бит! Ул арада Касыймов гаиләсе белән Алабугага күченергә дә өлгергән. Анда ул җирле халыкның яшәеш-көнкүрешен өйрәнә, янәшәдә генә урнашкан Бондюг химиклары белән якыннан аралаша, педагогия институтында лекцияләр укый — нәтиҗәдә «Томан аша», «Һаваларда тургай» роман-дилогиясе барлыкка килә.

Ә иҗат мөмкинлекләре һич кимеми, яшә дә яшә шушында тыныч кына. Юк шул, янында гына ГЭС, автогигант калка башлаганда, анда бөтен илдән яшьләр җыелганда, бу төбәк тормышның иң кайнап торган җиренә әверелгәндә, ничек тыныч яшәп ятарга була! Каләм әһелләреннән беренчеләрдән булып Э.Касыймов шунда күчеп төпләнә. Инде бай тәҗрибә туплаган язучы, вакытлы «урра-патриотизмга» артык бирешмичә, шул төбәктәге халыкны борчыган мәсьәләләр белән күбрәк кызыксына, әйтик, авылларның нигезеннән күчәргә мәҗбүр ителүенең кире яклары аны да борчый. Шуңа бәйле проблемаларны ул җентекләп өйрәнә. Шуларны хәл итү өчен кайгыртып, матбугатта публицистик әсәрләр яза. Иң мөһиме, ул материал сәнгати оеткы, мая булып та җыела килгән — яңа повесть, романнар языла.

Кайнар төзелешләрдә аралашу белән бергә 1965—1967 елларда Э.Касыймов Алабуга педагогия институтында татар фольклоры һәм татар әдәбияты курсын укыта. 1966 елда ул «Татар халык әкиятләрендә сатира һәм юмор» дигән темага диссертация яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала.

Бу елларда Э.Касыймовның әле телгә алган романнары рәтендә «Бир кулыңны, дустым!», «Көмеш язулы кылыч», «Сорбонна профессоры һәм без» повестьлары да басылып чыга.

«Сорбонна профессоры һәм без» повесте документаль нигезгә корылган: авторның яшь чагы, университет еллары... Үзәктә профессор Одинцов образы. Дөнья күләмендә танылган зур галим. Ләкин ул гаять катлаулы һәм драматик язмыш кичергән. Әсәр дәвамында вакыйгадан вакыйгага аның бик күп күркәм сыйфатлары ачылып укучы күз алдына килеп баса: зур эрудицияле галим булуы өстенә ул үтә нечкә күңелле, гаҗәеп оптимист җанлы кеше дә бит! Менә шул бик тә нечкә күңелле, йомшак табигатьле олы галим үз язмышында, юк, сөйгән ватаны һәм бөтен дөнья язмышында иң куркыныч, иң хәтәр чакны — фашизм дәһшәте алдында бил бөкми, баш ими, алай гынамы, көрәш юлына басып, зур фаҗигаләр кичерә... Андый кешегә чиксез ихтирам уянмыйча буламы соң! Повестьта профессор белән бергә бүтән геройларның да, аеруча студент Рифкатьнең (аны авторның үзе дип фаразларга



**Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җаваплы секретаре Эдуард Касыймов яшь язучылар Рәшит Юнысов, Рәшит Бәшәр белән.**
5 август, 1981 ел

да нигез бар) кешелек сыйфатлары ачылганнан-ачыла бара, карашлары ныгый, характерлары чыныга. Әсәр профессорның үлеме белән тәмамланса да, кешенең сынмас ихтыярына, аның рухи бөеклегенә үзенә бер мәдхия булып яңгырый, дип бәяләде бу повестьны заманында әдәбият белгечләре.

Бу елларда Э.Касыймов шулай ук «Томан аша» әсәренең дәвамы булган «Һаваларда тургай» романын тәмамлый. Бу әсәрләр дә укучы тарафыннан җылы каршы алына һәм, тәрҗемә ителеп, «Чулман — река внуков» исемендә роман-дилогия рәвешендә Мәскәүнең «Современник» нәшриятында рус телендә дә басылып чыга. Бу әсәр эшчеләр темасына язылган проза әсәрләре арасыннан. Бөтенсоюз күләмендә оештырылып килгән махсус конкурста ВЦСПС һәм СССР Язучылар союзы премиясенә лаек булган.

Чаллыда яшәү чоры аның иҗатын документаль әсәрләргә баета. Байтак кына очерк, кыска хикәя, мәкаләләр язып бастыра. 1979 елда аның «Советская Россия» нәшриятында Кама буе нефтьчеләренә багышланган «На Каме-реке» дигән очерклар китабы дөнья күрде.

Эдуард Касыймов күп еллар буена шеф-консультант сыйфатында автомобиль үзәгендәге «Ләйсән» әдәби берләшмәсенә җитәкчелек итә. Чаллы Язучылар оешмасы ачылгач, аның җаваплы сәркатибе булып эшли. Әдәбият өлкәсендәге хезмәтләре өчен һәм илле яше тулу уңаеннан әдибебез 1980 елда Почет Билгесе ордены белән бүләкләнде. Ул 1986 елның 21 мартында вафат булып, Чаллы зиратына күмелә.

Китаплары киләчәк буыннарга мирас булып калган. Ул мирас шактый саллы, күләмле. Сиксәненче еллар ахыры биеклегенә чигенеп бәяләгәндә, язучының татар әдәбиятына керткән өлеше дә, үтәлми калган вәгъдәләре дә, өметләре дә ачыграк күренә. Чынлыкта ул үз бәясен вакытында ала алмыйча дөнья куйган кызыклы, үзенчәлекле фидакарь шәхесләрнең берсе иде.

Язмабызның күренекле әдәбият белгече белән тәмамланган бу өлешен — әдип Эдуард Касыймовның тәрҗемәи хәленә һәм иҗат юнәлешләренә гомуми күзәтүне — башка чыганакларга да таянып, студентыбыз **Рузил Мингалимов** әзерләде.

## Публицистика кыйбласында

Каләм иясенең осталыгы кайсы жанрда иҗат итүенә карап та төрлечә ачыла.

Егерменче гасырның икенче яртысында татар әдәбиятында публицистик сулыш нык

көчәйде, тормыш чынбарлыгына — документальлеккә таяну әдәби-сәнгати алымнарның иң көчлесенә әверелде. Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, Миргазиян Юныс, Мәдинә Маликова кебек язучыларның барысы да иҗатны публицистика-журналистикадан башлап, чын сәнгать әсәрләре дә публицистика белән сугарылган язучылар иде. Ә Барлас Камалов, Кояш Тимбикова, Җәмит Рәхимов, Рахмай Хисмәтулла, Альберт Хәсәнов, Марсил Зариповлар бөтен иҗатлары баштан азагынача публицистика белән сугарылган язучылар сафын тәшкил итте — аларның берсен дә шул елларның журналистикасыннан аерып карау мөмкин түгел.

Эдуард Касыймов та шулар рәтендә дирлек иде. Моны дәлилләр өчен башка фактлар рәтендә аның үз сүзләрен китерү аеруча нигезле булыр. Аның әсәрләрен укыгач, уй-тойгылары белән уртаклашкан хатлар «Казан утлары» журналына да килә. Журнал шулардагы язучыга булган сорауларның җидесен аерып алып, аларга язучының җавапларын бастыра (Казан утлары, 1968, №10). «Әсәрләрегезнең прототиплары бармы?» дигән сорауга ул: «Барлык әсәрләремдә дә персонажларның прототибы бар, «Сорбонна профессоры»нда гына юк», — дип җавап бирә. Менә сиңа мә! Әле генә без «профессор» образы турында бик тә реаль, тормышчан образ дип, авторның Казан дәүләт университетында бергә укыган каләмдәшләренең фикерен җиткергән идек. Иҗат кыйбласы чын документальлек-публицистик булган әдип кенә шундый бәя ала ала-дыр.

Иҗатының башында ук ул реаль тормыш вакыйгаларын тасвирлауга алына. Мәсәлән, аның беренчеләрдән язылган «Ул Ленинградныкы иде» хикәясе («Үсү юлы», 1958, 13 нче китап), Ленинградтан эвакуацияләнеп, алар авылында төпләнгән урыс гаиләсенең сугыш хәлләре, авылда иләшү вакыйгаларын ничек булган шулай бәян итә. Шул ук вакытта ул бер караганда көндәлек булып тоелган вакыйга, күренешләрне гомумиләштереп, барлык кешеләрнең дә күпчелегенә тия торган сурәтләр белән тасвирлап, образ дәрәҗәсенә җиткерә алган.

Әлбәттә, публицистикада — иҗатның үзенчәлекле, катлаулы бер сәнгати юнәлешендә — документальлек бердәнбер асыл сыйфат түгел. Эдуард Касыймов әсәрләре мисалында аларның башкалары да ачык күзаллана. Әйдәгез, әдипнең публицистлык осталыгының кайбер «алтын баганалары»н барлап карыйк.

## Игътибарда — проблема

Публицистика үзәгендә кайнар проблемалар ярылып ята.

Эдуард Касыймовның шундый проблемаларга карашы турында бүгенге таләпләр яссылыгында студентыбыз **Зөһрә Миршәрипова** уйлана.

Гыйлемлек алга илтә. Проблемага мөнәсәбәте публицистның шәхси холкына-табигатенә, аның тормыш-яшәешенә, үзенә куйган таләпләренә нык бәйле. Эдуард Касыймов Казан университетының тарих-филология факультеты студенты чорында ук кешеләр белән мөлаем сөйләшә белү, тиз арада дуслашып китә алуы, иптәшләренең хәленә керә белүе, эчкерсез гадилеге, тыйнаклыгы һәм гаять активлыгы белән күзгә ташланып, дусларының күңеленә кереп кала.

Э.Касыймовның КДУда укыган чорында язылган «Сорбонна профессоры һәм без» миңа аеруча ошады. Чөнки мин үзем дә КДУ филиалында белем алам һәм монда укыган буыннарның тормышы безгә бик тә кызыклы.

Биредә язучы гыйлемлек проблемасын күтәрә. Әсәрне беренче мәртәбә укып чыккач, үземнең студент елларын шул чорныкы белән чагыштырып утырдым, университет тормышына чумдым. Ул ерак елларның татлы студент һавасын кабаттан сулагандай булдым. Элекке һәм хәзерге студент тормышы белән охшаш яклар да, аермлыклар да очрый. Охшаш якларның берсе дип гыйлемлелекне әйтергә була. Ләкин элекке чорда белемгә омтылу көчлерәк булган, минемчә. Ә хәзер барысы да акчага килеп терәлә... Шулай да хәзерге чор студентлары арасын-

да да «Сорбонна профессоры һәм без» әсәрендәге геройлар — Рифкать Кәримов, Вил Вахитов, Миша Черепанов кебек тырышлары да күп кенә.

Әсәр профессорның үлеме белән тәмамлана. Аның үлгән хәбәре бәян ителгән өзек миңа аеруча тәэсир итте, һәм күземә яшь тулды. Чөнки аның үлеме белән гыйлемлелек тә китеп барды сыман. Ул бит студентларны белемгә өндәүче иде. Әйе, профессор Одинцов студентларның әтиләренә әйләнгән иде. Ул аларга гыйлем иленә юл ачучы булды, дип әйтсәм дә ялгышмам.

Әсәрдәге гыйлемлелек проблемасын да автор нәкъ шушы герой аша бирә. Бу проблеманы ул шушы образ мисалында чишә дә. Аның тәэсирендә студентлар зур югарылыкларга ирешә. Кемдер университет доценты дәрәҗәсенә ирешә, кемдер мөгаллим булып китә.

Бу проблема бүген дә актуаль. Одинцов кебек шәхесләр, аз булса да, бүген дә бар. Безнең укытучыларыбыз арасында да. Алар бүген дә белемлелекне, гыйлем дәрәҗәсен үстерүгә зур тырышлык салалар.

## Саф һәм ярдәмчел мөнәсәбәтләр

Фольклор экспедицияләре биргән бай материалга таянып, язучы «Кояш көн дә чыга» повестен яза. Тумыштан сукыр кеше язмышының аянычлары, гаять авыр халәте, аңа төрле кешеләрнең төрлечә мөнәсәбәте һәм чын дусларының ярдәме белән, ниһаять, күзе ачылуы — болар һәммәсе дә әсәрдә ышандыргыч итеп сурәтләнгән. Автор кешеләрнең үзара мөнәсәбәтенең ни дәрәҗәдә саф һәм ярдәмчел булырга тиешлеге проблемасын алга китереп куя. Проблема тумыштан сукыр Абдулла образы ярдәмендә чишелә. Барлык геройлар да, Абдулланың кимчелегенә карамыйча, аны бик хөрмәтләп, яратып яши: хатыны Әзизә, кызы Җәмилә, Җәлүк бабай, колхоз рәисе Бикәшев, парторг Хәир Әхәтов һәм бигрәк тә авылның фольклорын өйрәнергә килгән Якуп Сәйфи — барысы да Абдуллага ярдәм итәргә, аны терелтергә ниятлиләр. Тик Кәрибулла гына аңа бүтән мөнәсәбәттә — аның сукырлыгыннан файдаланып, улы Гариф белән акча эшләргә исәп тота. Абдулла гармунда яхшы уйный, моңлы җырлый, димәк, хәер җыя ала. Бу мәкер турында белү Абдуллага бик начар тәэсир итә. Шулай да хатыны аңар күңелен сүрелдерергә юл куймый.

Һәрхәлдә, повестьта саф һәм ярдәмчел мөнәсәбәтләр өскә чыга — нәтиҗәдә Абдулла күрә башлый, дөньяның матурлыгына, гүзәллегенә шаһит була.

Әдипнең сафлык, ярдәмчеллек проблемасы бүген дә актуаль. Бүген дә Абдулла кебек тумыштан сукыр кешеләр бар, аларга ярдәм кулы сузу ихтыяҗы да җитәрлек. Тик, минемчә, элекке чор белән хәзергене чагыштырсаң, бу саф һәм ярдәмчеллек мәсьәләләре акчага кайтып кала.

Ватанны саклау — изге бурыч. Э.Касыймовның «Көмеш язулы кылыч» повесте, әдәби зәвык, тирән психологизм белән язылганга, күңелләрне тирәнтен дулкынландыра. Анда кешенең батырлыгы мәсьәләсе күтәрелә, героеның ватанны саклап калу бәрабәренә күргән җәфа, авырлыклары тормышчан чагылдырыла. Проблема Гыйлаҗ агай образы аркылы чишелә. Агай туры мәгънәсендә телсез: улы Бариның ипи тотып ант итеп сөйләвенә караганда, әтисенең телен, әсирлеккә эләккәч, сер бирмәгәне өчен явыз дошманнар кисеп алган, бөтенләй сөйләшә алмый...

Мондый «кимчелекле» геройга укучы игътибарын юнәлтер өчен «кылыч сюжетын» тәкъдим итә: ватанны саклаганда чиккән җәфалары өчен Гыйлаҗ агай кылыч белән бүләкләнгән икән. Аңа ул кылычны өендә тоту хокукы да бирелгән. Ул стенада төрле чәчәкләр чигелгән келәмдә, дәрәҗәле урында эленеп тора. Аның янында тагы авыл кешеләре «партүпәй» дип атаган каешлар да эленгән. Кылычның сабында ялтыравык калай кисәгенә матурлап уеп урысчалатып аның Гыйлаҗ абыйга сугышта зур батырлык күрсәткәне өчен бүләк ителүе язылган. Хәтта кайсы полк икәне дә теркәлгән... Күпләр, аеруча яшьләр, бу каза-

нышка чын горурлык кичерә. Авылыбызда тагын кемдә бар мондый кызык нәрсә, кемгә чын сугыш коралын тотарга хокук бирелгән!

Шул ук вакытта Гыйлаҗ агайның батырлыгына, бүләкнең чынлыгына шикләнүчеләр дә бар. Хәкимҗан агай, мәсәлән, «Имеш, аклар кисеп алган, ди. Булмастыр ла. Андый явызлыкка барырмы соң адәм баласы?»

Шулай да әдип оста алымнар белән Хәкимҗан агайны ышандыруга ирешә.

Әлеге проблема — Ватанны саклау бәрабәренә үзеңне корбан итү — хәзер дә вакытлы һәм урынлы. Бүген дә илебезне дошманнардан саклау ихтыяҗы көн кадагыннан төшмәгән.

Яшь чак — җүләр чак. «Бир кулыңны, дустым!» повестенда да Эдуард Касыймов яшьләр мәсьәләсен күтәрә. Әлбинә Әхсән исемле егетне ярата, ләкин алдана. Егет аны авырлы килеш ташлый. Ләкин Әлбинәгә дуслары ярдәмгә килә. Әйтик, Роберт аны электән үк яратып йөргән икән — хәзер инде авылга барып, аның «ире» дип белдерә...

Минемчә, автор бу әсәрендә яшьләрне нинди ялгышлыклар ясамаска икәнен кисәтә, яхшы дусларның нинди булырга тиешлеген тасвирлый. Биредәге вакыйгалардан бүген дә гыйбрәт алырга була. Бүген дә без мондый хәлләргә адым саен юлыгып торабыз. Шулай да кызлар уяурак булсын, беркатлы булмасын, дусларың чыннан да элекке яшьләр кебек тугры була белсеннәр, дигән теләктә калабыз.

* * *

Күренде ки, Эдуард Касыймов иң катлаулы проблемаларны чишү юлларын тасвирлауга да кыю алынган, бүгенге буын укучыларга да тәэсир итәрлек итеп тасвирлауга ирешкән. Ничек, нинди алым, ысуллар, нинди әдәби һәм публицистик чаралар белән?

Тасвир чарасы буларак очеркта кеше портретлары куллануны **Гөлназ Мансурова** өйрәнде.

# Портрет — тасвир чарасы

Эдуард Касыймовның иҗат мирасы шактый саллы, күләмле.

Уйлана торгач, башта бер гомуми нәтиҗә ясала: Э.Касыймовның һәр китабындагы төп геройлар, нәкъ тормыштагыча, каршылыклы булса да күпчелеге татар җанлы — әдәпле вә итагатьле кешеләр. Алар бүтәннәр хакына кереп, рәнҗетеп, үзләренә күбрәк мал төшерергә, җылырак фатирны, майлырак калҗаны эләктереп калырга ашкынмый, бераүгә дә этлек эшләргә, кемгәдер явызлык кылырга атлыгып тормый, чөнки андый максат аларның холкы-табигатенә туры килми. Э.Касыймовның яратып язган, җан җылысын кызганмыйча сурәтләгән геройлары, үзе шикелле үк, бүтәннәргә нинди дә булса изгелек эшләргә, мәрхәмәт күрсәтергә тырыша.

Э.Касыймов көчле кешеләр, үзләренә ияртерлек — соклангыч кешеләр турында яза.

Башта «Сорбонна профессоры һәм без» повестен искә төшерик. Язучы Рафаэль Мостафин: «Мин аны... укыгач, яңадан үземнең студент елларыма, үзем өчен бик тә кадерле булган университет тормышына чумгандай булдым. Әсәрдә байтак персонажларның исеме үзгәртелгән булса да, мин аларның бөтенесен диярлек күз алдына китердем: төс-кыяфәтләрен генә түгел, хәтта холык-фигыльләренә кадәр...»

Бу уңышта авторның портрет остасы булуы да искә алынырга тиеш. Профессор Одинцовның студентлар янына килеп кергәндә үк нинди кеше икәнлеге күзгә бәрелә: «Ачык калдырылган ишектә иң әүвәл сары күн портфель һәм трость, аннары ап-ак башлы картыбыз үзе күренде. Тукталып калды, чал кашлары астындагы зәңгәр күзләрен салмак йөрткәләп, безгә карады һәм, кисәк нигәдер тотлыгып-каушап, карлыкканрак тавыш белән исәнләште... Кафедра артына кереп басмады, каршыбызга, өстәл артына килеп утырды. Кулларын шәп күннән эшләнгән портфеленә куйды. Озын-нәзек бар-

маклары сизелерлек булып калтырый иде... Күпереп торган чал мыегы селкенеп алды — сәер генә итеп елмайды. Юк, аның бармаклары гына түгел, тавышы да калтырана — тамак төбеннән ничектер сызып-өзелеп чыга иде...»

Автор профессорның кыяфәтен, сөйләмен шундый оста иттереп сурәтли ки, шунда ук аның нечкә күңелле, яхшы кеше икәнлеген сизеп аласың. Әйтик, профессорның тактага ничек язуы аша да аның эчке һәм тышкы халәтенең ни дәрәҗәдә төрле булуын сурәтли.

Әдип портретны бәян иткәндә детальгә бик игътибарлы: «Менә, ниһаять, аның чал мыек тирәсе хәрәкәткә килде...» һ.б.

«Бир кулыңны, дустым» повесте герое Әлбинәнең чибәр, әдәпле, намуслы, эшчән, белемгә омтылучы кыз икәнен ул портреты аша да сурәтли: «Әлбинәнең Идел буенда туып-үскәнлеген әллә каян белеп була: әнә бит ул, аккош кебек җиңелчә тибрәнгәләп, йомры беләкләрен суга ничек тигез һәм ыспай салып бара...» Әдип әсәрдә аның «энҗе тешләрен», «озын керфекле карлыган күзләрен» ничәмә-ничә тапкыр кабатлый.

«Көмеш язулы кылыч» повесте герое Гыйлаҗны язучы бүтәннәрдән аерып куя. Беренче чиратта, мыек-сакалы белән. «...Шактый олы күренә иде: киң иягеннән асылынып төшкән дулкынланып торган каба сакал, чылгыйлары бөтерелеп торган хәтәр мыек, яссы маңгай астында бергә кушылып үсә язган яман да калын кашлар һәм болар һәммәсе дә сумаладай чем-кара төстә, тик сакал-мыегында гына көмеш төкләр күренгәли...»

Повесть яңа буын ирләрнең Бөек Ватан сугышына китүе белән тәмамлана. Көмеш язулы кылычына таянып баскан көенчә аларны озатып калган Гыйлаҗның мәһабәт сыны укучы күз алдыннан китми. Автор үз героена дастаннарга хас монументальлек бирә алган: «Гыйлаҗ агайны танырлык та түгел иде: өстендә күн тужурка, зәңгәр галифе, аягында күн итекләр, ә башында зур йолдызлы шлем. Күкрәгенең сул ягына кызыл тасма да кадаган... Тагы күкрәген аркылы-торкылы тар каеш, билен яссы каеш кыскан. Билендәге яссы каешта көмеш язулы кылыч асулы... Хәтәр кыяфәт!.. Менә ул каба сакалын як-якка борып китүче егетләр йөзеннән утлы карашын кичерде...»

Әлбәттә инде, тәҗрибәле әдип кешенең тышкы кыяфәтен сурәтләү белән генә чикләнми, моны үзмаксат дип тә санамый, ә бәлки бу чараны героеның эчке халәтен, рухи үзгәрешен, кичерешләрен, бөтен холкын ачып бирү, шулай итеп укучыга уңай тәэсир ясау өчен өстәмә чара буларак оста файдалана.

## Табигать һәм кеше — аерылгысыз

Бәян итүдә, тасвирлауда төгәллеккә ирешүнең янә бер сәнгати-публицистик чарасы — ул пейзаж. Аны куллануда да Э.Касыймов бай тәҗрибә туплаган. Һәр әсәрендә диярлек без соклангыч, күңелне җәлеп итәрлек манзара, күренешләргә юлыгып тәэсирләнәбез.

Әдәби әсәрләрдә портрет, интерьер, пейзаж ярдәмче вазыйфа үти. Әсәр мәйданында чагыштырмача аз урын били. Монда каләм остасы табигать манзарасының яки персонаж кыяфәтенең барлык детальләрен дә бөртекләп сурәтләүне мәҗбүри санамый. Аерым деталь, штрихларга гына басым ясау — аның өчен табигый хәл, ди әдәбият теориясе белгече. Ә менә Эдуард Касыймов әсәрләрендә табигать күренешләренә, аларның кешегә тәэсир итү очракларына зур урын бирелә: «Ишкәй елгасы диләр аны... Әллә кайларда, тау-таш араларыннан чылтырап бәреп чыккан чишмә сулары, урыс, мукшы, татар авылларының ямьле, киң тугайларында борглана-сыргалана, йомшак камыш үләннәрен тибрәндереп, әкренләп бергә кушыла баралар. Агым су, Апчатар үзәгендә тирән генә, матур гына елгага әверелеп, Ишкәй авылына килеп җитә, аның бакча артларындагы ярларга бәрелеп үтә, аннары үз юлында исемле һәм исемсез инешләр белән очрашып, талгын гына Идел кочагына барып керә...»

Беренчедән, бу пейзаж «Кояш көн дә

чыга» повестеның башламы буларак игътибарга лаек, димәк, укучы пейзаж күренешләрен әсәрнең буеннан-буена очратырга әзерләнә. Дөрестән дә шулай — аның өмете аклана. Персонажларның бөтен халәте диярлек табигатьтән аерылгысыз.

Икенчедән, табигать күренешләре әдәби әсәрдә хәбәр җиткерү бурычын да башкара ала. Алар вакыйганың нинди төбәктә, кайсы тирәлектә баруын искәртәләр. Җирле колоритны сиздерәләр. Моны без әлеге мисалдан да күрә алдык: Ишкәй елгасы, Апчара үзәне, Апкатар, Бүрәнә таулары һ.б.

Әгәр дә рәсем сәнгатендә тамашачы бөтен картинаны берьюлы, бер карап алу белән күрсә, әдәби әсәрдә исә язучы пейзаж, портрет күренешләрен акрынлап, эзлекле рәвештә, хәрәкәт дәвамында гына күрә һәм укучыларга да шулай тәкъдим итә. Эдуард Касыймов бу сәнгати закончалыкны төгәл үти.

Аның һәр әсәрендә төп герой табигать белән турыдан-туры мөнәсәбәттә: кеше аның йогынтысында яши, табигать аны сыный да. Геройның хис-тойгылары табигать күренешләре белән аерылгысыз үрелеп бара: «...Абдулла йомшак үләнгә яткан көйгә, гадәтенчә, төклетуралар безелди, үлән арасында чикерткә сызгыра, таллыкта аратирә саескан шагырдап куя... Абдуллага рәхәт бүген, күңеле шат аның...»

Пейзаж әсәрдә күп очракларда, бигрәк тә публицистик әсәрдә, характерның проблеманы чишү белән бәйле катлаулы халәтен ачыграк күрсәтергә, аны яхшырак аңларга ярдәм итә. Сүз белән әйтеп җиткерә алмаганны табигать күренеше, пейзаж ачык итеп, өстәмә чара буларак та күрсәтә ала...

Халык иҗатына якын, аны яхшы белгән иҗатчылар, гадәттә, табигатькә дә якын була икән. Эдуард Касыймовның пейзаж, табигать күренешләрен тасвирлау остасы булуын шуның белән дә аңлатып буладыр. Аны яхшы белгән каләмдәшләре әйтүенчә, авыл баласы буларак, үз туган ягын ул бик яраткан, якын иткән, аның табигатенә сокланып туя алмаган; оста балыкчы булган, балыкчылар турында китап та язарга хыялланган... Тик 1986 елның 21 мартында чишмә юлында әдипнең гомере өзелә.

Чишмә — әдәбиятта да мәңгелекнең шигъри-романтик образы. Эдуард Касыймовның йөрәге, шул рәвешле, чишмә типкән урында туктавы да үзенә күрә бик мәгънәле-символик образ булып кабул ителә. Аның әсәрләре дә халык күңелендә туктаусыз чылтырап торыр, дип ышанырга кирәк.

Яшьләрнең әдип иҗатында пейзажның әһәмиятле урын тотуына игътибар итүләре очраклы түгелдер. Бу темага берничә реферат язылды. Әлеге бүлекчәдәге фикерләр **Гөлшат Галиуллина, Ләйсән Гатауллина, Илнар Галиев** рефератларыннан алынды.

## Иң тылсымлы корал белән...

Ниһаять, Эдуард Касыймовның публицистик осталыгының иң нечкә, иң катлаулы «сер»ләреннән берсе — ана теле белән эш итү үзенчәлегенә тукталырга да вакыт җитте.

Иҗатының соңгы елларында Эдуард Касыймов нефть чыгаруны арттыру проблемасын хәл итүне тасвирларга алынды. Андагы катлаулы төеннәрне күз алдына китерү өчен белгечләргә генә мәгълүм схема, тамга, махсус терминнар, саннар һ.б. чаралар кирәк кебек. Шуларсыз сурәт ясап булмас шикелле. Була икән. Әдибебез моны телебезнең сүзләре, башка чаралары белән дә төшендерә алган: «...иң четерекле хәл Ык тамагындагы «Күлләр» чыганагындадыр, мөгаен. Анда катламдагы басымны күтәртмәсәң, нефть суыртуның күзгә күренеп кимүен көт тә тор. Димәк, катламга су кудырырга кирәк. Инде махсус скважиналары да борауланган. Әмма кудыру өчен Кама белән Ык суы бөтенләй яраксыз — пычрак. Иң кулае, әлбәттә, нефтькә ияреп чыккан тозлы су. Катламның үз суы... Кулаен кулай да, ләкин аны ныклап аерырга һәм тупларга кирәк. Чыганакның үзендә үк зур күләмле махсус резервуар кормыйча котыла алмыйсың... Шәүкәт Хәсәнов моны НГДУ җитәкчеләре алдына күптән куйган, күптән таләп итә. Ниһаять, төзүчеләр куба... Ләкин аларның эшләре ничек бара: акрынмы, шәпме?

Менә ни өчен Хәсәнов иң әүвәл Ык тамагыннан әйләнеп кайтырга ниятләде шикелле...»

Катламга иярчен су кудырып, нефть чыгаруны арттыру проблемасын язучыбыз үтемле генә итеп бәян итә дә бирә. Сурәтләү чаралары да элек халык сөйләмендә гомуми мәгънәдә киң кулланылган һәм нефть темасына бик урынлы терминлаша алган катлам, басымны күтәрү, су кудыру, чыганак, бораулау, суны аеру һәм туплау сүзләре һәм сүзтезмәләре үтә катлаулы техник һәм технологик күренешне дә ачык, үтемле итеп аңлатырга мөмкинлек бирә. Бу контекстта нефть, скважина, резервуар кебек татарның үз сүзләре булып күнегелгән термин берәмлекләр генә түгел, НГДУ кебек техницизм да сулышка тәртелмичә, җиңел «йотыла».

Әдипнең төгәллек чараларын барлаганда, аның деталь остасы икәнен инанасың. Аңарда деталь — гап-гади, барыбызга да таныш предмет яисә күренешнең нәкъ менә кирәкле урында, иң кирәкле вакытта әйтелүе, аның бер сыйфатын бик вакытлы, урынлы тотып алуы ул, укучының: «Карале, моны мин генә шулай дип белә идем, баксаң, язучы да белә икән», — дип, ачыш ясап, канәгатьлек кичерүе. Моңа да сүз-детальләр ярдәмендә ирешелә: «Минем бәхет басты. Махсус машинаның ябык кузовына менеп кунакладым да аның бәләкәй генә тәрәзәсенә борынымны төрттем. Кузгалдык...»

Әлбәттә, проблеманы чишү максатын куйган язучы да теманы ачканда аның бөтен нечкәлекләрен белеп бетерә алмас. Нефть чыгару кебек катлаулы процессларны белгечләр үзләре дә бүтәннәргә сурәтләп бирә алыр микән?! Язучы бит белгеч үк түгел. Мондый хәлдә аның ихласлыгы, шундый катлаулы техника, технологияне белгәнгә сабышмавы, шуны оста итеп бәян итә алуы — шул үзе төгәллек, конкретлык түгелмени! Монда әдип берничә алым куллана. Беренчедән, техниканы, процессны, ничек кенә булса да, белгечләр генә ачык аңлый торган күренешне гади укучы да күзалларлык сурәтләү чаралары таба. «Мирзанур... бер почмакта эленеп торган саклавыч тактадагы кнопкага баса. Кинәт бу авыр махина, бик каты дыңгырдап-ухылдап, хәрәкәткә килде һәм яньчелгән олы башын, тавык ашлык бөртеге чүпләгән сыман, әле күтәреп, әле төшереп, скважина тамагын «чукырга» керешге».

Икенче бер очракта ул бу хәлне белгеч кенә белергә тиешлеген, чыннан да төгәл белмәвен яшерми. Нәкъ менә шушы «наданлыгын» яшермәве, ачыктан-ачык әйтергә җөрьәт итүе белән ота да, конкретлыкка шуны ихлас сүзләр табып әйтә алуы белән ирешә дә. «Группалы установкада Мирзанур озаграк тоткарланды. Вентельләрне тыгызлады яисә бушата төште, нәрсәләрнедер сөртештерде, тазартты, аннары куен дәфтәренә нидер язып куйды...»

Шулай да конкрет төшендерү — язучының төп бурычы. Моңа ирешү өчен барлык иҗади сәләтен җигә. Шушы максаттан, мәсәлән, Эдуард Касыймов чагыштыруларның яңадан-яңаларын эзләп табарга остара. Бер генә мисал: «Группалы установка культбудка артындарак. Анда өч булит тора. Булит — сигарага охшашлы озын һәм юан чан ул. Аны, янтайтып, җирдән беркадәр күтәртеп салганнар...»

Күренешләрне, аеруча персонажларны ачык күзаллауда диалог, туры сөйләм, персонажның сөйләм үзенчәлеге дә зур урын тота. Мәсәлән «Ык тамагында» дигән очеркында төп персонаж Мирзанурның сөйләме еш кулланыла. Анда скважина, вахта, насос, парафин, смена, качалка, дебит, оператор кебек тарминнар, АДУ, РИТС кебек профессионализмнар, гади сөйләм элементлары булып китә башлаган кантур, начальство, напарник, уха кебек берәмлекләр дә сөйләмдә төгәллекне көчәйтүгә булышлык итә.

* * *

Шушы урында тукталып, без яшь иҗатчыларыбыз, яшь тикшеренүчеләребез публицист Эдурад Касыймовның иҗат казанышларын нәкъ менә үсү юлында, камилләшү юлында дип хис итеп, шушы кыйбладагы аның бай тәҗрибәсен киләчәктә дә өйрәнерләр, дип ышаныч белдерик.

**Илдар НИЗАМОВ,**
*публицист, Казан дәүләт университеты профессоры.*